ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:
а) унберенче абзацта «берәмлекләрдәге янгыннардан,» сүзләрен «берәмлекләрдәге, федераль территориядәге янгыннардан, ябык административ-территориаль берәмлекләрнең, федераль территорияләрнең» сүзләренә алмаштырырга»;
б) унбишенче абзацта «көчләре белән» сүзләреннән соң «торак пунктларында, шул исәптән шәһәр урманнарында» сүзләрен, «берәмлекләрдәге,» сүзләреннән соң «федераль территориядәге,» сүзләрен өстәргә;

2) 19 статьяның икенче өлешендә «гамәлләреннән» сүзеннән соң «, шулай ук федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә шартлау куркынычы булган предметларны эзләү, зарарсызландыру һәм (яисә) юкка чыгару эшләрен үткәрүдә, халыкара программаларны, проектларны һәм миналардан чистарту буенча гуманитар операцияләрне гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтүдә катнашудан, шартлату эшләрен башкарудан».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2022 елның 13 октябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 04 октябрь
№ 63-ТРЗ